КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 август г.Казань № 691

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны һәм хезмәтләр күләмнәрен раслау турында» 2018 ел, 1 сентябрь, 741 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарда:

«Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү» юлында «1 442,57» саннарын «1 442,56» саннарына алмаштырырга;

«Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү» юлында «Яше 40 ка кадәр булган» сүзләрен «Яше 40 ка кадәр булган, шулай ук маммография үтмәүче 40 яшьтән өлкән» сүзләренә алмаштырырга;

«Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү» юлында «Яше 40 ка кадәр булган» сүзләрен «Яше 40 ка кадәр булган, шәулай ук маммография үтмәүче 40 яшьтән өлкән» сүзләренә алмаштырырга;

«Яше 40 тан арткан маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү» һәм «Яше 40 тан арткан маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү» юллары үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә хезмәтләр күләмнәрендә:

«Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Яше 40 ка кадәр булган, шулай ук 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 70 184»; |

«Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Яше 40 ка кадәр булган, шулай ук 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 2 621»; |

«Яше 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү» һәм «Яше 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү» юллары үз көчен югалткан дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы балалар сәламәтләндерү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын үткәрүгә норматив чыгымнарны һәм хезмәтләр күләмнәрен раслау турында» 2019 ел, 4 март, 150 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы балалар сәламәтләндерү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын үткәрүгә норматив чыгымнарда:

«Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү» юлында «1 442,57» саннарын «1 442,56» саннарына алмаштырырга;

«Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү» юлында «Яше 40 ка кадәр булган» сүзләрен «Яше 40 ка кадәр булган, шәулай ук маммография үтмәүче 40 яшьтән өлкән» сүзләренә алмаштырырга;

«Яше 40 тан арткан хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү» юлында «Яше 40 тан арткан» сүзләрен «Яше 40 ка кадәр булган, шәулай ук маммография үтмәүче 40 яшьтән өлкән» сүзләренә алмаштырырга;

«Яше 40 тан арткан маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү» һәм «Яше 40 тан арткан маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү» юллары үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы балалар сәламәтләндерү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын үткәрүгә хезмәтләр күләмнәрендә:

«Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Яше 40 ка кадәр булган, шулай ук 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 789»; |

«Яше 40 тан арткан хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү» юлын

| | |
|---|---|
| «Яше 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 414»; |

«Яше 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү» һәм «Яше 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү» юллары үз көчен югалткан дип таныйрга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин